«Зәңгәр чәчәк» 6 нчы катнаш балалар бакчасы» муниципаль мәктәпкәчә бюджет бирү учреждениесе.

Проект эшчәнлеге

# **Тема:** “Светофор – безнең дустыбыз”

( уртанчылар төркеме өчен)



Төзеде: Мазитова Р. И.

FedotoVA



Кызыл, сары ут янганда
Сак булыгыз, балалар,
Хәвеф-хәтәр булмасын, дип,
Сезне кисәтә алар.

Ф.Ф. Әхмәдуллина

FedotoVA

1. Иҗади-эзләнү проекты.
2. Дәвамлылыгы: бер ай
3. **Максаты:** Балаларның светофор турында булган белемнәрен ныгыту, баету.

- **Бурычлар:**
- **Тәрбия бурычы:** балаларда итагатьлелек, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.
- **Үстерү бурычы:** балаларның юлда светофор төсләре буенча йөрү күнекмәләрен үстерү.
- **Белем бирү бурычы**: урам аркылы бары тик билгеләнгән урыннардан, светофорның яшел уты янгач кына чыгарга кирәклеген өйрәтү.





FedotoVA

# Проектны тормышка ашыру этаплары.

## Әзерлек этабы.

1) Проектның темасын уйлау;
2) Максаты кую;
3) Бурычлар билгеләү
4) План әзерләү
5) Ата-аналар өчен анкета



FedotoVA

## Төп этап.

1) Әңгәмә
2) Төрле төрдәге уеннар ( дидактик, хәрәкәтле, сүзле, үстерешле)
3) Рәсем карау
4) Экскурсия
5) Хикәя уку
6) Шигырьләр уку
7) Рәсем карау
8) Әвәләү
9) Конструкцияләү
10) Табышмаклар чишү



FedotoVA

# Йомгаклау

Эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау.



FedotoVA

# Перспектив – тематик план
# “ Светофор- безнең дустыбыз”

| № | Эшчәнлек тәртибе | Тәрбияче белән балаларның бер-дәм эшчәнлеге | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Әти- әниләр белән балаларның бердәм эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әңгәмә “ Свето-форның өч төсе” | Сорау- җавап | Д/у “ Юл бигеләре” | |
| 2. | Үстерешле уен “Төсле машиналар” | Уйныйлар | Уйныйлар | |
| 3. | Рәсем ясау “Светофор” | Табышмаклар чишү | Светофор ясыйлар | Өйгә эш. Төрле та-бигый материал-лардан светофор ясау. |
| 4. | Конструкцияләү “Светофор һәм машина” | Хәрәкәтле уеннар: “Светофор” | Төрле конструктор-лардан һәм короб-калардан “Светофор һәм машина” ясый-лар” | Өйгә эш: “Светофорның өч төсе” дигән темага рәсем ясау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Әти-әниләр б-н кичә “Юлда булыгыз уяу!” | Кичәгә кирәкле атрибутларны эзләү, җыр өйрәнү. “ Светофорлы юлларда”(В. Казыйханов шигыре, В. Әхмәтшин көе.) | _ | Кичәдә катнашу |
| 6. | Дидактик уен “Маймыл” | Уйныйлар | Уйныйлар | _ |
| 7. | Әвәләү “Светофор янында машина” | Уен уйнау “ Ярый, ярамый”. | Сюжетный композиөия “Юл, ма-шина, светофор” ясау | _ |
| 8. | Д/уен “ Бу нинди билге? ” | Уйныйлар | Уйныйлар | Урамда йөргәндә юл билгеләрен күрсәтәләр, аңлаталар. |
| 9. | Хәрәкәтле уеннар: “Үз төсеңне тап”, “ Машина килә” | Уйныйлар | Уйныйлар | _ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Шигырь уку.<br>Резеда Валиева “Күңелле светофор” | Сорауларга җавап бирәләр. | Тыңлау. | - |
| 11. | Табышмаклар чишү. | Җаваплар табу. | - | Юл билгеләре турыда табышмаклар уйлап табу. |
| 12. | Хикәя уку | Сорауларга җавап бирәләр. | Эчтәлеген үз сүзләре белән сөйләү. | “ Бер көнне светофор..” дигән темага әкият уйлап чыгару. |
| 13. | Шигырь уку .<br>Зәки Нури “Урам чык-канда булган хәл”. | Сорауларга җаваплар бирәләр. | Тыңлыйлар. | - |
| 14. | Якындагы светофор янына экскурсия. | Светофорның эшен күзәтү. | Күзәтәләр. | Консультация: “Урамда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре”. |

# «Адымнар нык, юллар имин булсын!»

Алып баручы: Исәнмесез, балалар! Исәнмесез хөрмәтле әти - әниләр, апалар, абыйлар! “Зәңгәр чәчәк” балалар бакчасында бүген бәйрәм – гаилә бәйрәме! Без бүген, әти-әниләр белән бергәләп, күңел ачарга җыелдык. Без бит бергә- бер зур гаилә. Барыбыбызның да максатыбыз уртак – нәниләребез сау- сәламәт, таза, нык, акыллы булып үссеннәр иде.

Без олы юлга, зур сәфәргә чыгабыз. Сәфәребез дәвамында иң өлгер, иң тапкыр, иң зирәк команданы билгеләргә тиеш булабыз. Төркеме балалары һәм әти-әниләре ике тигез командага бүленә. Әйдәгез, алар белән танышып китик .

*( командалар, бер- бер артлы басып, команданың исемен, девизын әйтәләр: беренче – “Яшел ут”, икенче – “Шаян җәяүле”.*

*Алып баручы кунакларны һәм кичәдә катнашучыларны жюри әгъзалары һәм уенның кагыйдәләре белән таныштыра.)*

Алып баручы: Дуслар, әйдәгез, татар халкының бетмәс-төкәнмәс хәзинәсенә күз салыйк әле. Халкыбызның зирәк акылы иҗат тикән мәкальләрен искә төшерик. Кайсы команда иң күп мәкаль әйтә - шул җиңүче була.

*Икенче бәйге “ Табышмак- зиһен ачкычы” дип атала. Табышмакның җавабын балалар әйтергә тиеш, алар җавап бирә алмаганочракта әти-әниләр ярдәм итәргә.*

*“ Яшел ут” командасы, игътибар белән тыңлагыз:*

*Юл чатында тора батыр,күзләре төрле-төрле,*
*Берсен йома, берсен ача- аны белә һәр кеше.*

*(светофор)*

Дөрес, балалар, бу- светофор- юл хәрәкәтен көйләп торучы. Без аны ихтирам итәргә тиеш. Тагын бер табышмакны тыңлагыз, анысы “ Шаян җәяүле” командасына.

Ике мөгезле, теле юк, йөгергән юлда эзе юк.

Нәрсә ул? ( Троллейбус.)

( *Алга таба* һәр командага транспорт төрләре турында табышмак әйтелә).

Нинди гаҗәеп өй бу? Һәр ягы тәрәзәле,
Аягында резина, бар ашаганы бензин.
Бу нинди өй? ( Автобус).

Тәрәзәле һәр ягы, җиргә тими аягы.
Сыртында бар дугасы, йә, бу нинди юрга соң. ( Трамвай.)

Балалар, транспорт төрләрен бик әйбәт беләсез икән. Җавапларны тиз таптыгыз. Бик зирәкләр икәнсез. Ә хәзер уйлап алабыз.

**“Светофор” уены.**

Минем кулда 3 флагчык, алар- светофор төсләрендә. Кызыл флагчык күтәрелсә- бер-берегезгә бармак янагыз. Сары флагчык күрсәгез- бер урында атлап торыгыз.Яшел флагчыкны күтәрсәм-биерсез. Килештекме? Бер , ике, өч- уен башланды!

Алып баручы: Дуслар, бүген иртән хат ташучы миңа бер хат тапшырды, ләкин ул бик серле хат булып чыкты. Анда язылган сүзләрнең мәгънәсен бер дә аң-лый алмадым. Бәлки ярдәм итәрсез? Әгәр сүзләрнең мәгънәсен төшенә ал-сагыз, аны бөтен команда белән бергә хәрәкәт аша күрсәтегез, ярыймы?

*Алып баручы конверттан сүзләр язылган кәгазьләр ала һәм командаларга бирә.*

*“Тёломас» сүзе чыккан команда самолёт булып «очып күрсәтә», «йовмарт»-трамвай булып «йөри».*

**Алып баручы**: Бүгенге бәйгедә әти-әниләрнең иң зирәкләре, иә зиһеннәре катнаша икән. Булдырдыгыз! Рәхмәт сезгә барыгызга да! Ә хәзер эстафетауеннары башлый-быз. Кайсы команда җитезерәк булыр икән? Эстафета 4 этаптан тора. Һәр этапта бер бала һәм беролы кеше катнаша. Димәк, командадан барлыгы 8 кеше кирәк. Эстафе-таны башлыйбыз.

1. этап: бала һәм олы кеше, агач атка “атланып”, билгеләнгән урынга кадәр йөгереп баралар һәм, кире йөгереп килеп, эстафета таягын икенчепарга тапшыралар.
2. этап: өч көпчәклек велосипедта бала утырып бара, олы кешеаңа булыша.
3. этап: уенчык машинага утырган баланы олы кеше этеп алып бара.
4. этап: һәр команда кара төстәге турыпочмаклы кәгазьләр һәм кызыл, сары, яшел түгәрәкләр бирелә. Тиз генә светофор “төзергә” кирәк.

**Алып баручы**: Сез беләсезме икән: Россия беренче юл билгеләре 1909 нчы бардыкка килгән. Алар бары тик 4 кенә буллганнннар. Хәзер алар бик күп. Кичә-нең алдагы соравы капитаннат өчен. Алар күрсәтелгән юл билгеләрен танып әйтергә тиешләр.

“Сак булыгыз- балалар!”, *“ Янәшәдә телефон”, “Җәяүлеләр юлы”* дигән билгеләр күрсәтелә.

**Алып баручы:** Капитаннар юл билгеләрен яхшы беләләр.Алар белән зур юлга чыксаң да була, ышанычлы, белемле юлдашлар.

*Капитаннар конкурсыннан соң өй эше тикшерелә: һәр команда светофор турындаүзе уйлап чыгарган әкиятне сөйли.*

**Алып баручылар:** Бу биремне дә әти-әниләр, балалар зур осталык белән башкарып чыктылар. Рәхмәт аларга!

“Юлга чыкканда юлдашың үзеңннән дә яхшырак булсын” дигән халкы-быз. Әйе, юлда яхшы юлдаш бик кирәк. Ә инде үзеңә юлдаш итеп җыр да алсаң, әллә нинди озын юллар да кыска тоела, вакыт тиз уза. Алдагы ярышыбыз – җыр бәйгесе.

*Командалар, чиратлашып, юл, транспорт төрләре, дуслык турында ырлар җырлыйлар.*

**Алып барычы**: Күңел ачу кичәбез тәмамланып та килә. Без көн дә юл йөрибез,сәфәр чыгабыз. Юлларыбыз хәвеф-хәтәрсез булсын дисәк, юл йөрү кагыйдәләрен беркайчан даистән чыгармыйк. Юлларда үзебезне әдәпле, тәртипле тотыйк. Бүгенге күтәренке күңел, бердәмлек көндәлек юлдашыбыз булсын.

*Кичә ахырына сүз жюри әгъзәләренә бирелә. Ярыш түбәндәге номинацияләр буенча бәйләнә: “ Иң бердәм”, “ Иң җитезләр” .*

*Бәйрәм дуслык турында җыр белән тәмамлана.*